| | | |
|---|---|---|
| **Каралган**<br>МБ җитәкчесе<br>_______ /Нәҗметдинова Л.Ә./<br>Беркетмә № 1<br>«25»август 2014 ел. | **Килешенгән**<br>«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ<br>_______ /Сәгъдиева Г.Ф./<br>«25»август 2014 ел. | **Раслыйм**<br>«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры<br>_______ / Әхмәтшина Л.М./<br>Приказ № 94<br>«27»август 2014 ел. |

Уку фәненнән

ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Әхмәтшина Лариса Михаил кызы, югары категорияле укытучы

татар әдәбияты, 9 нчы сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

**Аңлатма язуы**

**9 нчы сыйныфта** татар әдәбиятыннан эш программасы түбәндәге документларны нигезләнеп төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ” )
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбиятыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа
5. “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан программа” (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013 ел.
6 Ә.М.Закирҗанов, Г.М.Фәхретдиновалар төзегән Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан авторлык (эш) программасы.
7. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 №лы хаты (04.09.2014.)
8. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
10. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы положениесе (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

**Укытуның төп максаты** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Беренче һәм икенче баскычларда күрсәтелгән максатка ирешүне тагын да камилләштерү: халыкның гасырлар буена бөртекләп җыела килгән акыл һәм рухи байлыгын өйрәнүне дәвам итү.
2. Татар әдәбиятын тарихи нигездә чорларга бүлеп өйрәнү.
3. Гомумкешелек кыйммәтләре һәм конкрет тарихилыкның тыгыз мөнәсәбәтен аңлау юнәлешендә әсәрләр уку, аларны анализлау һәм шәрехләү.
4. Милли горурлык тәрбияләү, халкыбыз үткән тарихи чорлар һәм шул чорда язылган әдәби әсәрләр аркылы үз халкыңның тарихын, гореф-гадәтләрен, психологиясен тирәнрәк үзләштерү.

Матур әдәбият - йогынтылы сәнгать. Тик шулай да аңа тылсым көче бирелмәгән. Чынында исә, матур әдәбиятның башка берни белән дә алыштырып булмый торган мөстәкыйль әһәмияте һәм билгеләмәсе бар. Ул халыкларның гасырлар буена бөртекләп җыела килгән акыл һәм рухи байлыгын тәшкил итә. Әлбәттә, рухи хәзинә язма сүз сәнгате белән генә чикләнми. Әдәби әсәрләрнең төп төзү материаллары булган тел үзе генә дә иңләп булмастай дәрьяны хәтерләтә.

Билгеле, программада аны бөтен тулылыгы белән чагылдыру мөмкин түгел. Биредә БДИ биргәндә һәм укучылар күңеленә якын булган, милли төбәк компонентларын искә алып төзелгән әсәрләр өйрәнүне **максат** итеп алынды.

Югары сыйныфларда гомумкешелек кыйммәтләрен һәм конкрет тарихилыкның тыгыз мөнәсәбәтен аңлау юнәлешендә әсәрләр уку, аларны анализлау һәм шәрехләү максат итеп куелды.

Матур әдәбият, иң әүвәл, кешене, аның эчке дөньясын сурәтли, кешенең башкаларга , табигатькә, җәмгыятькә, яшәешкә мөнәсәбәтен күрсәтә. Аның төрле үсеш чорларында бу сурәтләүләр, мондый мөнәсәбәтләр төрле сыйфат алган, үзенчәлекле булган. Төрле чор әдәбиятларын, язучыларын, әсәрләрне асылда кешегә кешелекле, миһербанлы мөнәсәбәт яки кешегә кешелексез, кимсетүле караш, аларның сыйфаты аерып тора, үзенә генә хас билгеләр белән бизи яки чуарлый. Укучыларга менә шуларны җиткерү минем тагын бер **маскатым** булып тора.

Кыскасы, татар әдәбиятын укытуның ***төп максаты*** - чыгарылыш сыйныфларында укучы татар балаларының мәктәптә уку дәвамында тупланган тел, лингвистик, коммуникатив компетенциясен билгеләү.

**<u>Эш программасының бурычлары:</u>**

Бу юнәлештә эшне уңышлы алып бару өчен, түбәндәге **бурычлар** куела:

1. Аерым әсәрләрдә һәм язучылар иҗатында чагылган гомумкешелек мәсьәләләренә тарихи якын килеп, укучыны матур әдәбияттагы “мәңгелек” проблемаларны аера һәм бәяли белергә өйрәтү.
2. Үткәндә иҗат ителгән әсәрләрне бүгенге чор белән бәйләп карау.
3. Матур әдәбиятның иң әүвәл кешене, аның эчке дөньясын сурәтләвен, кешенең башкаларга, әйләнә-тирә мохиткә, җәмгыятькә, яшәешкә мөнәсәбәтен күрсәтүен аңлату.
4. Төрле чор әдәбиятларын, язучыларын, әсәрләрне өйрәнү барышында аларның кешегә кешелекле яки кешелексез мөнәсәбәт, миһербанлы яки кимсетүле караш аерып торганлыгын, һәр чорның үзенә генә хас билгеләре булганлыгын төшендерү.
5. Матур әдәбиятның сәнгатьнең башка төрләре кебек үк иҗтимагый аңның бер тармагы, кешелек тарихының төрле дәверләрен сәнгатьчә теркәп баручы үзенчәлекле елъязма булуы хакында күзаллау булдыру.

Программада монография һәм күзәтү төсендәге темалар аралаштырып бирелә. Мондый аралаштыру укучыларны сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң яхшы әсәрләр белән якыннан таныштыра, мондый әсәрләрнең тарихи-әдәби процесста тоткан урыны билгеләнә. Монографик темалар тормышны киңрәк күрсәтүне үз эченә ала һәм бу бер язучы иҗатына киңрәк тукталу аша ирешелә. Мондый темалар икегә бүлеп карала, ләкин һәр икесендә дә әдәби әсәр тестын тирән үзләштерү бурычы куела:

1. Тормыш, шул чор һәм язучы мирасы җентекләп өйрәнелә.
2. Язучы иҗаты кыскарак бирелә, ләкин андый әсәрләрдә кешенең (әдәби геройларның) холык-психологиясендәге яңа яклар ныграк ачыла.

Програмада әдәби әсәрләрне өйрәнгәндә укучыларның сөйләм телен һәм язу культурасын үстерүгә һәрчак игътибарлы булуны күздә тоткан эшләр дә алынды. Укучыларның мөстәкыйль әдәби иҗатка омтылышларын мөмкин кадәр үстерү өчен иҗади биремле эшләр (БДИга хәзерлек максатыннан) минем мөһим бурычларымның берсе.

**Уку фәненә бәяләмә**

Сүз сәнгате булган әдәбият – тормышны үзенчәлекле танып белү формасы, ул хисси-эмоциональ тәэсир чаралары ярдәмендә дөнья сурәтен, моделен төзү һәм шуңа карата мөнәсәбәт формалаштыру сәләтенә ия. Мәктәптә укыту предметы буларак ул әхлакый-эстетик һәм интеллектуаль әзерлекле шәхес, гражданин тәрбияләүдә турыдан туры катнаша. Укучы әдәби әсәрләр, аларның авторлары фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен,

халыкның рухи байлыгын үзләштерә - тормыш фәлсәфәсенә төшенә. Шуңа күрә гомуми белем бирү системасында бу укыту предметының әһәмияте зур. Татарстан Республикасының “Телләр турындагы Законы”ына нигезләнеп, татар әдәбияты фәне ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планының төп урынны били һәм мәҗбүри укытыла торган фәннәренең берсе булып тора.

Матур әдәбиятның башка берни белән дә алыштырып булмый торган мөстәкыйль әһәмияте һәм билгеләмәсе бар. Ул халыкның гасырлар буена бөртекләп җыела килгән акыл һәм рухи байлыгын тәшкил итә.Әлбәттә, рухи хәзинә язма сүз сәнгате белән генә чикләнми. Әдәби әсәрләрнең төп төзү материалы булган тел үзенә дә иңләп булмастай дәрьяны хәтерләтә. Болар янына тагын халкыбызның көе-моңы, көлү чаралары һәм биюе, рәсем һәм сәхнә сәнгате, матбугат фәлсәфәсе , мәгърифәте, гореф-гадәтләре һәм уен- йолалары ,әхлак принциплары , тарихи истәлекләре, ювилер- һөнәр осталыгы һәм башкалар килеп кушыла. Матур әдәбият - әнә шул җанга якын, газиз олы хәзинәнең бик мөһим өлеше ул.

Программа асылда тарихи-эстетик принципка нигезләнә.Һәр сыйныфта иң әүвәл жанрлар буенча фольклор үрнәкләре өйрәнелә, аларның поэтик-фәлсәфи мәгънәсе төшендерелә, халык авыз иҗаты әсәрләрен күңелдә сакларга, язып алырга киңәш ителә, кызыксыну тудырыла. Шуннан соң фольклор белән билгеле бер бәйләнештә туган язма әсәрләр тикшерелә.Шуларга тарихи-хронологик тәртиптә халык тормышының төрле якларын чагылдырган башка әсәрләр ялганып китә.

Бу курста күренекле язучыларның иҗатын өйрәнү елдан-ел тирәнәйтелә бара. Югарырак сыйныфка күтәрелгән саен , аларның яңадан-яңа әсәрләре кертелә. Һәр яңа баскычта укуытучы аларны балаларның хәтерендә яңарта, арасында бәйләнеш җепләре суза һәм, шулай итеп, иҗат турында бөтен бер караш тудырырга омтыла.

Сүз сәнгате дәресләрендә сәнгатьле текст өч төргә бүлеп өйрәнелә:

1)текстны җентекләп тикшерү(уку һәм анализлау)

2)Гомумирәк тикшерү (укып фикер алышу)

3)мөстәкыйль үзләштерү(сыйныфтан тыш уку)

Бугенге әдәбиятны киңрәк иңләү нияте белән, кайбер әсәрләр һәм әдипәэр иҗаты вариант тәртибендә тәкъдим ителә.

Программада әсәрләрнең табигатен , төп хасиятен аңларлык, матур әдәбиятның үзенчәлекләрен белеп калырлык дәрәҗәдә теоретик төшенчәләр тәкъдим ителә. Югары сыйныфларда алар тирәнәйтелә.

Әдәбиятның бурычы әдәби әсәрләрне бала күңеленә сеңдерүдән, аларның мәгънәсен , нәфислеген төшендерү, укучыларда күркәм сыйфатлар тәрбияләүгә булышу, әсәрләрне күбрәк укырга теләк уятудан һәм тәрбияләүдән гыйбарәт.

**Татар әдәбияты фәненең укыту планында тоткан урыны**

Региональ базис укыту планында татар әдәбияты фәнен укытуга 350 сәгать каралган, шуның 68 сәгате (атнага 2 сәгать) 9 нчы сыйныфта татар әдәбиятын укыту өчен бирелә. Татар мәктәбенең **9 нчы сыйныфында** татар әдәбияты дәресләре программа нигезендә атнага 2 дәрес исәбеннән барлыгы 68 сәгатькә каралган

ТР Минзәлә муниципаль районы МБГББУ “Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2014-2015 нче уку елына укыту планында да 68 дәрес ( атнага 2 сәгать) бирелгән.Эш программасы шуларга нигезләнеп 68 дәрес(атнага 2 сәгать) исәбеннән төзелде. Программада “Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре өчен (5-9) татар әдәбиятыннан үрнәк программа файдаланылды һәм аның ярдәмендә темаларга үзгәреш кертелде.

ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы буенча татар әдәбияты укыту фәненең мәҗбүри өлешендә (базовый уровень) өйрәнелә. Уку-укыту планы 9 нчы сыйныфта татар әдәбиятын укыту ана теле һәм әдәбиятын укытуның **икенче баскычына** ( 5-9 нчы

сыйныфлар) туры килә. Бу чорда тормышның төрле өлкәләренә караган, төрле һөнәр ияләренең язмышларын чагылдырган әдәби әсәрләр белән танышуга, аларны тиешенчә аңларга, матурлык ноктасыннан бәяләп кабулитәргә өйрәнүгә игътибар ителә. Халык авых иҗатының төрле төрләренә, аларның үзенчәлекләренә игътибар ителеп, фольклор белән әдәбият арасындагы тыгыз бәйләнеш күрсәтелә. Укучыларның сөйләм телен үстерүгә зур урын бирелә, әдәбият теориясеннән башлангыч мәгълүмат бирелә. Шулай ук 9 нчы сыйныфтан башлап инде татар әдәбияты чорларга бүлеп тә өйрәнелә башлый.

Татар мәктәпләрендә татар әдәбияты фәнен укыту буенча УМК юк. Әдәбият дәресләре Х.Й.Миңнегулов, Ш.А. Садретдиновлар төзегән "Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен әдәбият дәреслеге" (Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2006 нчы ел) һәм "Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нче сыйныфы өчен әдәбияттан хрестоматия" буенча укытыла.

Өстәмә әдәбият буларак А.Г.Әхмәдуллин төзегән "9 нчы сыйныф өчен өстәмә әдәбият" (Казан, "Хәтер" нәшрияты, 2000 нче ел) җыентыгы кулланыла. Яңа программага туры килгән яңа дәреслекләр булмау сәбәпле, шулай ук агымдагы уку елында татар мәктәпләренең 10 нчы һәм 11 нче сыйныфлар өчен чыгарылган (академик А.Әхмәдуллин редакциясендә) дәреслекләр һәм хрестоматияләр дә кулланыла.

**<u>9 нчы сыйныфка килгәндә, укучылар түбәндәгеләрне белә:</u>**

1. Әсәрләрне әдип сүзләре белән үз сүзләреңне дә кушып мөмкин кадәр төгәл сөйли белү.
2. Әсәрләренң табигатен, төп хасиятен аңларлык, матур әдәбиятның үзенчәлекләрен аңлата алырлык дәрәҗәдә программада бирелгән теоретик материалны белү.
3. Гади һәм катлаулы план төзи белү. План нигезендә сочинениегә материал туплау, аны билгеле бер эзлеклелеккә китерү.
4. Сөйләм төрләрен (сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү) аеру, шуларга туры китереп, сочинениеләр язу.
5. Телдән монологик һәм диалогик формаларда сөйләм төзү.
6. Теләсә нинди берәр хәл яки вакыйга хакында телдән һәм язма эзлекле сөйләм төзү.
7. Сочинение һәм башка язмаларны камилләштерү (тулыландыру, редакцияләү).
8. Укыган текстка сораулар төзү.
9. Программада ятлау өчен бирелгән текстларны яттан белү ***("Идегәй" дастаныннан өзек "И Идел йорт,Идел йорт...", Ш.Бабич "Халкым өчен", Һ.Такташ "Алсу", М.Җәлил "Кичер, илем!", Р.Фәйзуллинның бер шигыре)*** **.**
10. Укыган әсәрләргә карата үз фикереңне белдерү һәм башлангыч анализ ясый алу.
11. Әдәби әсәргә яки аның бер өлешенә рецензия яза белү.
12. Өйдә мөстәкыйль укыган әсәрдән идея һәм проблеманы аерып чыгара белү.

**<u>9 нчы сыйныфта бирелә торган һәм уку елы ахырына укучылар белергә тиешле осталык һәм күнекмәләр:</u>**

1. Әдәбиятның чорларга бүленешен белү.
2. Чорларга хас билгеләрне белү һәм чорларга тарихи-мәдәни күзәтү ясау.
3. Программада бирелгән язучылар һәм аларның әсәрләре турында белемнәр булу.

4. Программада бирелгән әдәбият теориясен белү.
5. Текст яки укучылар сайлаган бер тема нигезендә сөйләү һәм төп уйны, тема, идеяне аерып ала белү, аны мисаллар нигезендә аңлату.
6. Бер әсәргә яки аның бер өлешенә рецензия язу һәм аны камилләштерү.
7. Сөйләмә һәм язма формаларда сочинениеләрне, сөйләмнең төрле төрләренә туры китереп, төрле жанрда язу. Аларны тулылыандыру һәм стилистик яктан шомарту.Сочинениеләргә күзәтү ясый белү.
8. Әдәби әсәрләрне чор белән бәйләп анализлый алу.
9. Әдәби әсәрнең теленә бәя бирә белү.
10. Әдәби әсәрнең жанрын тану.

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына, күнекмәләренә таләпләр; контроль төрләре. Күнекмәләр формалаштыру**

Укучыга билгеле бер күләмдә белем бирү белән янәшә, аларны ныгыту, күнекмә дәрәҗәсендә беркетү кирәк була. Әдәбият шикелле белемнәр анализлау-тикшерү барышында үзләштерелә торган предмет өчен бу аерата мөһим. **Күнекмәләр булдыру** эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдә үстерелә һәм бәяләнә:

- **рецептив эшчәнлек**: әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләү; сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау.

- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, бәяли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.

- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; рольләргә кереп кабатлап бирү; план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә язу, сочинение элементлары белән изложение язу; әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу.

- **эзләнү эшчәнлеге**: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирү.

- **тикшеренү эшчәнлеге**: әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау; тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:
- сүз сәнгатенең образлы табигатен;
- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларыннан Г.Тукайның, Г.Камалның, Г.Ибраһимовның, Ф.Әмирханның, Г.Исхакыйның, М.Җәлилнең, Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын;
- өйрәнелгән әсәрләрнең эчтәлеген;

- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- төп әдәби-теоретик төшенчәләрне

**белергә**;

- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап, аерым өлешләрен яттан сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең аерым якларын элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын билгеләү;
- әдәби әсәрләрне, аларның геройларын чагыштыру;
- геройларга характеристика бирү, автор позициясен ачыклау;
- сәнгатьле уку;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару

**күнекмәләрен** үзләштергән булырга тиеш.

Укучыларның уку барышында алган белем-күнекмәләрен бәяләп бару укыту процессының мөһим өлешен тәшкил итә, аның әһәмияте, максаты укучыларның белемнәрен даими күзәтеп, бәяләп бару белән билгеләнә.

**Уку** күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: әдәби текстны аңлап, дөрес, йөгерек һәм сәнгатьле уку, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес интонация һәм басым белән уку, текстның төп мәгънәсен, эчтәлеген аңлап, эчтән уку һәм кирәкле информацияне табу һ.б.

**Сөйләм** күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең эчтәлеген бәян итү яки тәкъдим ителгән аерым өзекләрен яттан сөйләү, әсәрнең геройлары, вакыйгалары турында текст төзеп, хикәяләп сөйләү, бирелгән темага хикәя төзеп сөйләү, язучының биографиясе, язучы иҗаты хакында сөйләү, әсәргә карата үз мөнәсәбәтен җиткерү, автор текстына нигезләнгән монологик сөйләм әзерләү, аерым әсәрләр, әдипләр, әдәби күренешләр һ.б. хакында сөйләшү.

**Язу (язма сөйләм культурасын)** күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр: әдәби әсәр буенча куелган сорауларга язмача җавап әзерләү, әсәргә мөстәкыйль бәяләмә, сочинение элементлары белән изложение, сочинение һәм әсәргә яки билгеле бер темага мөнәсәбәтле хикәяләр һ.б. язу.

**Анализ күнекмәләрен һәм теоретик белемнәрне** бәяләү өчен биремнәр: әсәрнең төр һәм жанр үзенчәлекләрен табу, геройларга, образлар системасына бәя бирү, автор һәм хикәяләүченең вазифасын ачыклый алу, образларның мәгънәләрен табу, стиль, тел-сурәтләү чараларын табу һәм тексттагы функциясен билгеләү, сюжет барышын тикшерү, сюжет элементларын табу, тема-проблема, идеяне билгеләү, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру һ.б.

Әлеге бирем төрләреннән тыш, укучыларның белем, күнекмәләрен тикшерү максатыннан тестлар, тест тибындагы биремнәр куллану да уңышлы санала. Тестларның уңайлылыгы аларны тикшерү эшен тиз, төгәл оештырырга, дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны чагыштырырга мөмкинлек бирә, моннан тыш, укучыга татар әдәбиятыннан бердәм дәүләт (республика) имтиханына әзерләнү барышында да ярдәм итә ала.

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре**

Гомуми төп белем бирүче мәктәпләрдә татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда әдәби әсәрне аңлау-бәяләү күнекмәсе булдырыла, әхлакый позиция һәм эстетик зәвык тәрбияләнә, иҗади фикерләү үстерелә, һәм болар дөньяга карашны, тормышны бәяләү чарасына әверелергә тиеш.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми (метапредмет) нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;
- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;
- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:

- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*эстетик яктан*:

- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;

- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

Бүгенге яшүсмер укучы алдагы буын укучылардан нык аерыла, телевидение, радио, интернет һ.б. бик күп мәгълүмат чаралары тирәлегендә үскән һәм тәрбияләнгән бала бай мәгълүматлы була, әмма еш кына әлеге мәгълүматлар аның рухи дөньясына тискәре йогынты да ясый. Шуңа күрә **шәхси нәтиҗәләр** арасында түбәндәгеләре аерым әһәмияткә ия:

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предметара нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;
- татар теленә бәйләнештә, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү.

**Төренә, максатына карап, әдәбият дәресләрендә түбәндәге педагогик технологияләр кулланыла:**

* модульле-блоклы
* аңлату-күрсәту; репродуктив, проблемалы укыту методы, өлешчә эзләнү (эвристик) методлары;
* үстерелешле укыту технологиясе;
* проблемалы укыту;
* дифференциаль укыту
* тикшерү- проект
* ИКТ

### Әдәбият фәненең эчтәлеге

Урта сыйныфларда әдәбият укыту әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән укып танышу һәм аларны өйрәнү, тикшерү–анализлау һәм нәтиҗәләр ясауга, бәяләүгә йөз тота. Укучыларда язучыларның тормышы, иҗаты турында (биографик), әдәбият тарихы, аның төрле

этаплары, аерым чорлар әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләр, язучылар турында өстәмә, әдәби әсәрне, иҗатны тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик, әдәби әсәрне чор белән бәйләп характерлаучы, чорның сыйфатларын, төп кыйммәтләрен табу өчен кирәкле мәгълүматларның тупланууы мөһим.

Урта сыйныфларда татар әдәбиятының аерым чорлары үзара бәйләнешле өйрәнелә башлый, аерым фольклор үрнәкләре, аларга анализ аша поэтик-фәлсәфи йөкләмәне, эчке, субъектив мәгънәне табу күнекмәләре формалаштырыла – болар әдәби иҗатка карата күзаллау булдыруда катнаша. Әдәби үрнәкләр белән танышу эше өч төрдә алып барыла: аерым әдәби әсәрләр уку һәм анализлау, аерым берләре укып фикер алышу, кайберләре сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителә. Әмма һәр очракта да алда куелган критерий һәм таләпләр истә тотыла.

Әдәбият тарихы

***Әдәбият тарихын*** өйрәнү халык авыз иҗатыннан башлана.

Халык авыз иҗаты

Халыкның милли, рухи мәдәният хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең үзенчәлекле сыйфатлары, аларда гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык авыз иҗатында образлар бирелеше. Фольклорда дөнья сурәте: каһарманлык, яхшылык һәм явызлык, яшәеш һәм кеше, кеше һәм табигать хакында күзаллаулар.

Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары. Әкиятләр, жанрлык сыйфатлары, жанр төрләре. Җыр жанрына хас сыйфатлар. Җырларны төркемләү. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүз. Кыска жанрлар: табышмаклар, мәзәкләр, мәкальләр һәм әйтемнәр. Бәетләр. Риваятьләр һәм легендалар, аларга хас үзенчәлекләр. Мифлар. Мифларның килеп чыгышы хакындагы карашлар. Мифларны төркемләү. Татар халык мифлары. Дастан жанрына хас сыйфатлар.

Халык авыз иҗаты поэтикасы (фантастик яки мифологик сюжет һәм детальләрдәге чынбарлыкка охшату; сурәтләү чаралары буларак кабатлау, каршылык, чиктән тыш арттыру, кечерәйтү, чагыштыру һ.б.). Татар халык авыз иҗатының башка халыклар фольклоры белән аваздашлыгы һәм аермалы яклары.

Әдәбиятның барлыкка килүе, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнешләре. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе.

**Борынгы, Урта гасырлар һәм XIX гасыр татар әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Тотрыклы мотивлар: гадел идарәче, мәрхәмәтлелек, игелекле исем–ат, әхлаклылык, камил инсан һ.б. Урта гасырлар әдәбиятында романтик мотивлар. Үгет–нәсыйхәтчелек.

Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**XX йөз — XXI йөз башы татар әдәбияты**

XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

1920-1930 елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте.

XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

“Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары” укучылар үзләштерергә тиешле язучыларны, аларның әсәрләрен һәм әдәбият теориясеннән темаларны гомумән күрсәтү белән чикләнә. Аларның **эчтәлеге** дәреслекләрдә ачыла. Әдәбият дәресләрен тел дәресләре белән тыгыз алып бару күздә тотыла. Бу укучылар сүзнең мәгънәсен, кулланыш үзенчәлеген, “тәмен” дөрес тоярга өйрәнсен өчен эшләнә. Әдәбият дәресләрендә темаларны өйрәнгәндә, түбәндәгеләргә аеруча игътибар ителә:

1. Программада бирелгән берничә монографик теманың барсы да яки берсе генә сайлап алып та өйрәнелә.
2. Күзәтү төсендәге темаларны өйрәнү барышында чорның үзенчәлекләре белән дә таныштырыла.
3. Билгеле бер чордагы әдәби агымнар һәм юнәлешләр, язучыларның төрле төркемнәре, бу чорда әдәбият аеруча игътибарлы булган мәсьәләләр һәм кеше характеры турында мәгълүматлар бирелә.
4. Бу чордагы иң күренекле әсәрләрнең кайберләре укучыларга мөстәкыйль укып танышу өчен тәкъдим ителә.
5. Әдәби әсәрләр өйрәнгәндә, укучыларның сөйләм телен һәм язу культурасын үстерү күздә тотыла.
6. Телдән һәм язма рәвештә үткәрелә торган эшләрнең төрле төрләреннән файдаланыла.
7. Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә игътибар ителә.

Программа нигезендә үтелергә тиешле төп темаларга дәресләр бүленеше түбәндәгечә:
Барлык дәресләр саны – 68
Әсәрләрне өйрәнү – 53 дәрес
Сөйләм үстерү –7 дәрес
Дәрестән тыш уку –6 дәрес
Кабатлау өчен дәресләр - 2

9 нчы сыйныфта татар әдәбиятының Борынгы һәм Урта гасырлар чорыннан алып 19 нчы йөзгә кадәрге татар әдәбияты чорларга бүлеп өйрәнелә:

**Кереш. Татар әдбиятының чорларга бүленеше (1сәг)**

**Төрки-татар әдәбиятының чыганаклары (4 сәг)**

-Татар әдәбиятының халык авыз иҗаты һәм мифология белән бәйләнеше. Фольклордан килә торган аваз-мотивлар һәм сәнгатьлек ысул-чаралары, алымнары.
-рун язулы истәлекләр. “Орхон-Енисей” язмалары”нда алга таба әдәбиятта үстерелеш тапкан фикер-мотивларның чагылыш.
-Уйгур язулы истәлекләр.

**Болгар чоры әдәбияты (4 сәг)**

-Идел-Кама буендагы Болгар дәүләте. Анда мәдәниятнең чәчәк ату үзенчәлекләре. Әдәбият һәм сәнгатьнең югары сыйфатын дәлилләгән фактлар.

- Урта гасырлар әдәбиятында дастан жанры. Иҗатта традицияләр һәм яңалык.

**Алтын Урда чоры әдәбияты ( 2 сәг)**

-XIIIйөз урталарыннан алып XV йөз башына кадәр дәвердә болгар-татар мәдәнияте, әдәбияты һәм сәнгатенең торышы турында кыскача мәгълүмат бирү. Бу чор әдәбиятында иҗтимагый тормышның, сәяси һәм икътисади хәлләрнең чагылышы. Төп мотивлар һәм геройлар.
- Дидактик әдәбият турында төшенчә. Поэтик тәрҗемә, аның милли әдәбияты үстерүдәге роле.
-Әдәби багланышлар. Жанр төре һәм жанр формасы буларак газәл, касыйдә. Шигырьләрдә рифма үлчәүләре турында мәгълүматлар.

**Казан ханлыгы чоры әдәбияты (2 сәг)**

-Казан ханлыгында әдәбиятның үсеше, аңарда иҗтимагый һәм сәяси хәлләрнең чагылу дәрәҗәсе.
-Сүз һәм графика сәнгатенең үзенчәлекле чагылышы буларак кабер ташлары (эпитафия). Легенда һәм риваятьләр. Аларда җәмгыять тормышының кайбер якларыгәүдәләнү һәм бу чор кешесенең рухи дөньясы чагылу үзенчәлекләре.
-Лирик герой турында төшенчәне киңәйтү.

**XVII йөздә әдәбият (2 сәг)**

-Бу чор илдәге иҗтимагый-сәяси шартларның татар әдәбиятында үзенчәлекле чагылышы.
-Татар милләтенең хәле: милли дәүләтчелек бетү, татар халкының колониаль коллыкка эләгүе. Моның мәдәниятkә, әдәбиятка тәэсире. әдәбиятта татар халкының азатлык көрәше чагылу, мондый әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше.
-Шигырь төзелеше турында урта сыйныфларда белгәннәрне искә төшерү һәм тагын да тулырак мәгълүмат бирү.
-Поэзиядә стилистик фигураларның урыны һәм роле.

**XVIII йөздә әдәбият (2 сәг)**

- Бу чор- татар әдәбиятында халыкның иҗтимагый-икътисадый хәле чагылу дәрәҗәсе, әдәбиятның халык тормышына якыная баруы. Азатлык дәрәҗәсе, әдәбиятның халык тормышына якыная баруы. Азатлык көрәшләрен сыфатлаган әсәрләр.

- Сүз сәнгатенең үзенчәлекле гәүдәленше буларак Батырша хатлары. Пугачев хәрәкәтнең халык авыз иҗатында һәм язма әдәбиятта чагылуы.

**XIX йөзнең беренче яртысында әдәбият (1 сәг)**

-XIX гасырдагы татар әдәбиятына кыскача бәяләмә-кереш. Татар әдәбияты һәм милләт тарихы. Җәмгыять тормышына, мәгърифәт үсешенә тәэсир иткән фактлар. (Казанда университет һәм типографияләр ачылу). Татарларның Россия һәм Европа эшләренә күбрәк катнашуы.1812 елгы Ватан сугышында активлыклары. Декабристлар хәрәкәтендә татарлар. Милли тормышка торган саен ныграк тәэсир иткән европалашуның сүз сәнгатендә чагылуы. Бу чор әдәбиятында ике баскыч.

-Татар поэзиясенә һәм сәнгатьле фикерләү рәвешенә шагыйрьләр керткән яңалыклар.

**Габделҗаббар Кандалый (2 сәг)**

-Язучының тормыш юлы. Кандалыйның шәхес буларак үзенчәлекләре, сыйфатлары.

-Беренче әдәби әсәрләре.

-Кандалыйның беренче шигырьләрендә уздырылган фикерләрдә хөрлекне яклау авазлары. Искелеккә, фанатизмга каршы булу.

- Г.Кандалыйның алга таба иҗатында дөньяви мәхәббәтнең төп темага әверелүе. Бу теманы эшкәртүдә шагыйрьнең әдәби традицияләргә

**XIX йөзнең икенче яртысында әдәбият ( Яңа әдәбиятка күчеш чоры) (2сәгать)**

-XIX гасырның икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә татарлар арасында иҗтимагый хәрәкәтнең җанлануы, моңар аерым гыйльми җәмгыятьләрнең, башка халыкларның алдынгы карашлы галимнәрнең йогынтысы.

-И.Гаспралы турында мәгълүмат бирү. Көнчыгыштан килә торган алдынгы карашлар һәм фәлсәфи тәгълиматлар тәэсире.

-Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылышы. Реализмның ныгый башлавы. Мәгърифәтчелек реализмы формалашу. Аның төп билгеләре һәм сыйфат үзенчәлекләре. Әдәбиятта чагылган гомумкешелек кыйммматләренең реаль эчтәлек ала баруы.

-XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында гомуми бәяләмә-күзәтү. Идеаль башлангыч урынына реаль башлангыч килү.

-Әдәбиятның халыкчанлыгы төшенчәсен киңәйтеп аңлату.

**Каюм Насыйри иҗаты – ( 3 сәг)**

**Татар прозасының реализм нигезләрендә җитлегү чорына керүе - (1 сәг)**

- Прозада жанрларның камилләшә баруы, яңа жанрлар һәм жанр төрләре барлыкка килү (роман, повесть, сатирик хикәя). Төп темалар һәм проблемалар, аларның мәгърифәтчелек рухында хәл ителеше.

-Уңай һәм тәнкыйди юнәлешләрнең ачык төс алуы.

-Татар әдәбиятының “күп гасырлар Шәрыкъ тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына Гареб тәэсире астына” (Ф.Әмирхан) керә башлавы һәм моның прозада чагылышы.

-Язучыларның милләт язмышы турында уйлануларында яңалыклар.

**Заһир Бигиев (3 сәг)**

-Әдипнең тормыш юлы. Киң белемле, алдынгы карашлы дөнья әдәбиятын яхшы белгән, аерата төрек һәм француз әдәбиятлары белән кызыксынган зыялы рухани булып җитлегүе.
**-“Өлүф яки Гүзәл кыз Хәдичә”** романында саф мәхәббәт белән байлык арасындагы каршылык тудырган хәлләрнең тормышчан итеп тасвирлануы.
-“**Гөнаһе кәбаир**” романы турында кыскача мәгълумат.
**-“Мәвәраэннәһердә сәяхәт”** әсәре турында мәгълүмат бирү.
-Роман жанры турында өстәмә мәгълүмат. Сюжет һәм композиция.

**Мифтахетдин Акмулла (2 сәг)**

- Татар, казакъ, башкорт әдәбиятларының уртак вәкиле. Акмулланың хат алымы белән язылган шигырьләре, алардагы төп фикерләр, поэтик үзенчәлекләр.
- -Акмулла-чичән шагыйрь. Аның хикмәтләренең төп сыйфатлары: кыскалык, тапкырлык, образлылык.

**Яков Емельянов (2 сәг)**

Иҗаты турында белешмә бирү. Бу иҗатта дини мотивлар. Шигырьләрендә гражданлык рухының көчәя баруы. Җәмгыятьнең байлар һәм ярлыларга бүленеүеннән ризасызлык, гади кеше хәлен реалистик буяулар белән тасвирлау.
Лирик геройның рухи халәтен тасвирлауда яңалыклар.
-Шигырьләренең халыкчанлыгы, тел-сурәтләү чараларының гади образлылыгы, ритмика ягыннан байый һәм төрләнә баруы.

**Татар драматургиясенең беренче адымнары(2 сәг)**

-Жанр формалашу. Драматургиядә Көнчыгыш әдәбиятлары һәм Урта гасыр татар әдәбиятыннан килә торган хыялый-романтик рухны дәвам иттерү.
-Беренче сәхнә әсәрләрендә мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләре, саф әдәп-әхлак кагыйдәләрен яклау, тормыш һәм гореф-гадәтләрне тәнкыйтьләү.

**9 нчы сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак (1 сәг)**

**Әдәбият теориясеннән түбәндәгеләрне өйрәнү күздә тотыла:**

1. Матур әдәбиятның милли үзенчәлеге.
2. Матур әдәбиятның иҗтимагый вазифасы.
3. Урта гасырлар әдәбиятында дастан жанры. Иҗатта традицияләр һәм яңалык.
4. Дидактик әдәбият. Поэтик тәрҗемә. Газәл, касыдә. Рифма үлчәүләре.
5. Лирик герой.
6. Поэзиядә стилистик фигуралар.
7. Жанр төрлелеге. Мәдхия, мәрсия.
8. Әдәби бәйләнешләр. Әдәби иҗатта күчемлелек.
9. Шигырь үлчәмнәре.
10. Мәгърифәтчелек реализмы.

11. Әдәбиятның халыкчанлыгы.
12. Ритм һәм рифма турында төшенчә.
13. Драма, комедия.

Аерым ***биремнәргә*** килгәндә:

-Татар халкының милли казанышлары буларак татар әдәбияты. Татар әдәбиятының бөтендөнья матур әдәбияты, аерым алганда төрки әдәбиятлары арасындагы урыны. Коръән һәм татар әдәбияты тарихын чорларга бүлү;

- Сүз сәнгате буларак матур әдәбият, аның тел үзенчәлекләре. Тезмә һәм чәчмә сөйләмнәр. Халык авыз иҗаты һәм әдәбият. Әдәби телләр һәм жанрлар.

-Образлылык-әдәби әсәрнең төп сыйфаты; сәнгатьле сурәтләүнең асыл чаралары.

-Әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм төзелеше (тема,идея, сюжет, композиция, образлар системасы).

-Матур әдәбитятагы мәңгелек темалра һәм “мәңгелек образлар”. Андагы әхлакый һәм тарихи-мәдәни проблематика (алла һәм кеше, изгелек һәм явызлык көрәше, кеше һәм җәмгыять, кеше һәм табигать, буыннар мөнәсәбәте4 намус, туганлык, бурыч һәм вәгъдәгә тугырылык, ватанпәрвәрлек, мәхәббәт һ.б.)

-Әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре арасындагы мөнәсәбәт.

-Әдәбият тарихы. Әдәби процесс. Әдәби тәнкыйть.

-Әдипләрнең иҗат үзенчәлекләре турында татар әдәби тәнкыйте.

-Әдәби әсәрдә тормыш материаллары һәм сәнгатьле уйланманың үзара мөнәсәбәте. Матур әдәбиятта милли үзенчәлек һәм гомумкешелек кыйммәтләре.

-Классик әдәбият әсәрләренең үз чоры һәм бүгенге көн өчен әһәмияте.

-Әдәби төрләр һәм төп жанрлар. Әдип карашларын чагылдыруга хезмәт итүче алымнар, сәнгатьчә сурәтләү чаралары. Әдәби әсәр һәм аның төзелеше. Стиль төшенчәсе.

-Әдәби юнәлешләрнең һәм иҗат методларының(мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, романтизм, социалистик реализм) үзенчәлекле билгеләре.

-Татар мәдәниятында милли, әхлакый, ратихи- мәдәни мәсьәләләр. Кеше һәм җәмгыятькеше һәм вакыт,кеше һәм табигать, кеше һәм Алла; бәхет, яшәү мәгънәсе һ.б. турында эзләнүләр, табышлар.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы №12138/13 хаты (07.09.2013), шул хатка әдәбият фәнен укыту буенча №12192/13 (09.09.2013) аңлатмасы һәм татар теле укытучыларының район методик берләшмәсе карары нигезендә (Беркетмә № 2, 09.09.2013 нче ел) программага түбәндәге әсәрләр кертелде һәм аларга дәресләр саны һәм төре түбәндәгечә бүленде:

**Барлыгы – 20 дәрес**

**XX гасыр башы әдәбияты**

Ф.Әмирханның «Хәят» повесте. – 3 сәг

Г.Камалның «Банкрот» комедиясе. – 3 сәг

М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр). - 3 сәг

**БВС чоры әдәбияты**

Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере. -1 сәг

Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе. – 1сәг

**Яңа үзгәрешләр чоры әдәбияты**

Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» шигырьләре. – 2 сәг

А.Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте. – 3 сәг

Т.Миңнуллинның «Кулъяулык» музыкаль драмасы. (мөстәкыйль уку өчен) – 1 сәг (ДТУ)

Ф.Садриевның «Таң җиле» романы (өзекләр)- 1 сәг (ДТУ)

Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре.(ДТУ) – 1 сәг

**Бәйләнешле сөйләм үстерү өчен барлыгы** 7 сәгать вакыт бирелә.

Шулар арасында әдәбият дәресләрендә программа буенча түбәндәге эш төрләрен үтәү каралган:

- Бирелгән әдәби образларга чагыштырма бәяләмә бирү.
- Сочинениеләргә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү.
- Берничә шигыре мисалында шагыйрьиҗаты турында күзаллау булдыру һәм шулар нигезендә язма сөйләм – сочинение язу.
- Портрет яки туган як табигате җирлегендә сочинение-хөкем йөртү, сочинение-сыйфатлама, сочинение – хикәяләү язу.
- Берәр өй сочинениесен һәм дәрестә язган сочинениене бергәләп тикшерү һәм анализлау.
- Программага кертелгән әсәрләр яки алардан сайланган өзекләрне сәнгатьле итеп уку, эчтәлекне төгәл, кыскартып яки киңәйтеп сөйләү.
- Укыган әдәби әсәргә рецензия язарга өйрәнү.
- Әсәргә катлаулы план төзү, шул план нигезендә диалогик һәм монологик сөйләмнәр төзү.

**Әдәбият теориясе**

**Әдәби төр һәм жанрлар.** Эпос, лирика һәм драма төрләре. Жанр. «Жанр хәтере». Эпик жанрлар: роман, повесть, хикәя. Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Шәркый жанрлар системасы. Драма жанрлары: комедия, трагедия, драма. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә.

**Сәнгать төре буларак әдәбият**. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.

**Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Лирик герой, хикәяләүче, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Табигать образы, әйбер образы, мифологик образ, фантастик образ, архетип.

**Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Текст: эпиграф, багышлау, көчле позиция.

**Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Лирик чигенешләр. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. Шигырь төзелеше. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж. Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

**Әдәбият тарихы.** Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият.

**Әдәби барыш.** Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты.

**Укучыларның укуын һәм белем-күнекмәләрен бәяләү.**

Укучыларның 1 минутка уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:

| | Иҗек саны | | Сүз саны | |
|---|---|---|---|---|
| | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык |
| V | 155-235 | 160-250 | 65-105 | 70-110 |
| VI | 160-250 | 170-270 | 70-110 | 75-115 |
| VII | 170-270 | 180-280 | 75-120 | 80-125 |
| VIII-IX | 180-280 | 190-290 | 80-125 | 85-130 |

**Искәрмә.** Эчтән уку тизлеге, кычкырып уку белән чагыштырганда, 5-7 нче классларда – 30-40 % ка, ә 8-9 нчы классларда 40-50 % ка югырырак була.

Уку барышында үтәлергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>- фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>- татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>- җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр – иҗекләргә, җөмлә - сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>- тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса,<br>- интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “5”ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | | |
| 1.<br><br><br><br><br><br>2. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>- кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>- сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>- җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “4”ле билгесе куела. |
| 1.<br><br>2.<br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br><br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | “3”ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда. | “2”ле билгесе куела. |

**Телдән җавапларны бәяләү.**

Телдән җавап бирү – тәкъдим ителгән теманы сөйләү формасында була.

М а т е р и а л:

1) программа материалы буенча бирелгән яисә үзе сайлап алган тема;

2) эчтән укылган текстның (нигездә, әдәби әсәрдән яисә әдәбият дәреслегеннән алынган, күрсәтелгән яисә үзе сайлап алган) эчтәлеге.

С ө й л ә ү г ә б и р е л ә т о р г а н в а к ы т:

V - VI класста 2-5 минут.

VII класста 3-6 минут.

VIII класста 4-7 минут.

IX класста 5-7 минут.

X - XI классларда 7-10 минут.

**Әдәбият дәфтәренә таләпләр**

Әдәбият дәфтәрендә һәр уку елы дәвамында түбәндәге төп язмалар була:

1) планнар

2) эчтәлекне хикәяләп язу
3) цитаталар (күчереп язу)
4) аңлатмалар (сүз һәм төшенчәләргә)
5) фикер язмалары (үз фикереңне язып кую)
6) укучы үзе иҗат иткән әдәби әсәрләр (хикәяләр, шигырьләр, мәзәкләр, сценарийлар һ.б )
7) халык авыз иҗатыннан җирле материаллар
8) аннотацияләр һәм рецензияләр( 9 кл.)
9) тезислар ( 9 кл.)
10) конспектлар (9 кл.)
11) рефератлар ( 9 кл.).

Әдәбият дәфтәрендә бары тик программа материалын үзләштерүгә һәм аны язып бирә белергә өйрәтә торган язмалар гына булырга тиеш. Язма эшләр сочинение таләпләре белән бәяләнә.

Әдәбияттан белем дәрәҗәсен бәяләү соңгы чиктә сочинение яздыру белән йомгакланса да, өлгереш билгеләре чыгарган вакытта аның белән генә чикләнмичә, уку, сөйләү, телдән җавап бирү дә исәпкә алына.

**Укуга карата төп таләп – сәнгатьле уку.**

<u>Уку материалы:</u>
1. Укучы үзе язган текст яки сочинение.
2. Әдәби әсәрдән, публицистик һәм фәнни хезмәттән өзек.

<u>Материалның күләме:</u>
Һәр класс өчен билгеләнгән сочинение күләме икеләтә алына.

<u>Материалны сайлап алу:</u>
1. Укучы үзе сайлый, үзе теләгән текстны укый.
2. Укытучы күрсәтмә бирә.

<u>Укуны әдәбият фәне буенча бәяләү өчен таләпләр:</u>
1. Уку тел (грамматика) фәне буенча уңай билге куярлык булсын.
2. Сәнгатьле яисә логик сәнгатьле (текстның характерыннан чыгып) башкарылсын.
3. Уку интонациясен бөтен текстка һәм аның аерым өлешләренә карата укучы аңлатып бирә белсен.

И с к ә р м ә. Уку интонациясен аңлатканда:
1. V – VII классларда интонациянең текст эчтәлегенә карата булган ягын аңлату җитә (ягъни объектив эчтәлектән чыгып).
2. VIII класста авторның тексттагы эчтәлеккә мөнәсәбәтен чагылдыру дәрәҗәсенә бәйләп аңлату да таләп ителә.
3. IX - XI классларда укучы, болар өстенә, текст эчтәлегенә үзенең мөнәсәбәтен, тыңлаучыларга ничек тәэсир итәргә, аларда нинди хисләр уятырга теләгәнлеген дә аңлатырга тиеш.

Соңгы ике таләптән берсенең үтәлмәве тел буенча куелган билгене – бер баллга, икесенең дә кимчелекле үтәлүе билгене ике баллга киметә. Икесе дә бөтенләй үтәлмәгән булса, әдәбияттан “2”ле куела.

**Минутка укыганда куела торган таләпләр**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>-фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>-татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) саклanса;<br>-җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр-иҗекләргә; җөмлә-сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>-тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә язылса;<br>-интонацион яктан тестктагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларга төгәл җавап бирелсә; | “5”ле куела |
| 1 | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>-кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>-сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>-җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-32 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирсә | “4”ле куела |
| 1<br><br>2 | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик,2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлек булса; | “3”ле куела |
| 1<br>2<br><br><br>3 | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда; | “2”ле куела |

**Сочинение бәяләү нормалары**

| № | Эшнең эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
